**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**15 июнь 2015 ел** **№ 18**

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлегендә өченче чакырылышка
Совет депутатларын сайлау турында

"Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, "Мюд авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясына нигезләнеп, Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлеге Советы **КАРАР** кабул итте:

1. 2015 елның 13 сентябренә өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауны билгеләп куярга.

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча «Сельская Новь» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://Aksubayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам .

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге
Совет Рәисе: А.Г.Семенушкин